ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 570-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 570-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2024 елның 11 июле
№ 2584-VI ДС

проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кетрелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**«Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

**1 статья**

«Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында» 2006 елның 24 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 7 (I часть); 2012, № 7 (I часть); 2013, № 7; 2014, № 6 (I часть), № 6 (II часть), № 12 (II часть); Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2019, № 2 (часть I); 2021, № 93 (часть I), 2022, № 57 (часть I) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«Инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен аерым эш төрләрен (һөнәрләрне) резервлау турында»;**

2) преамбуланы үз көчен югалткан дип танырга;

3) 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1 статья. **Инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен аерым эш төрләрен (һөнәрләрне) резервлау турында закон**

Инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен аерым эш төрләрен (һөнәрләрне) резервлау турында закон Россия Федерациясе Конституциясенең, Татарстан Республикасы Конституциясенең тиешле нигезләмәләренә нигезләнә һәм федераль законнардан, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларыннан, Татарстан Республикасы законнарыннан һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларыннан тора.»;

4) 2 статьяның 3 пунктында:

а) җиденче абзацта «күп балалы ата-аналар,» сүзләреннән соң «уллыкка алучылар, опекуннар (попечительләр)» сүзләрен өстәргә;

б) сигезенче абзацта «Чернобыль һәм башка» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) тугызынчы абзацка «(әлеге гражданнар бу чорда хәрби хезмәткә чакыру буенча хәрби хезмәтне үткән очракта - хәрби хезмәткә чакыру буенча хәрби хезмәтне үтү тәмамланганнан соң)» сүзләрен өстәргә;

г) унынчы абзацка «һәм азат ителгәннән соң бер ел дәвамында эш эзләүче затлар» сүзләрен өстәргә;

5) 3 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Инвалидларны эшкә алу өчен квота Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы эш бирүчеләр өчен, халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы башкарма хакимиятнең федераль органы тарафыннан расланган методик тәкъдимнәргә ярашлы рәвештә, хезмәткәрләрнең исемлектәге уртача саныннан процентлар буенча түбәндәге күләмдә билгеләнә:

1) хезмәткәрләренең саны 35 кешедән алып 100 кешегә кадәр булган, 100 кешене кертеп, эш бирүчеләргә – хезмәткәрләрнең исемлектәге уртача саныннан 2 процент күләмендә;

2) хезмәткәрләренең саны 100 кешедән артык булган эш бирүчеләргә – 3 процент күләмендә билгеләнә.

Икътисадый эшчәнлекнең төрле төрләре, Татарстан Республикасының төрле муниципаль берәмлекләре өчен инвалидларны эшкә кабул итү өчен квота күләме дифференциацияләнми.»;

б) $1^1$ өлештә «хезмәткәрләрнең» сүзләреннән соң «алдагы квартал өчен» сүзләрен өстәргә;

в) $1^2$ өлешкә «хезмәткәрләрнең» сүзләреннән соң «алдагы квартал өчен» сүзләрен өстәргә;

г) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Инвалидларны эшкә алу өчен билгеләнгән квотаны үтәүдән эш бирүчеләр түбәндәге очракларда азат ителә:

1) әгәр алар инвалидларның иҗтимагый берләшмәләре булса;

2) Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән башка очракларда.»;

д) 3 нче өлеш үз көчен югалткан дип танырга;

е) 11 һәм 12 өлешләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Эш бирүче тарафыннан инвалидларны эшкә алу өчен билгеләнгән квотаны үтәү Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртип нигезендә тәэмин ителә:

1) инвалид белән эш урынына турыдан-туры эш бирүчедә хезмәт килешүе төзелгән очракта;

2) инвалид белән оешма арасында, шул исәптән инвалидларның иҗтимагый берләшмәләре һәм алар оештырган оешмаларны да кертеп, шул исәптән хуҗалык

ширкәтләре һәм устав (склад) капиталы инвалидларның иҗтимагый берләшмәсе (алга таба – башка оешма) кертемнәреннән торган җәмгыятьләр арасында яки инвалидларны эшкә алу өчен квота билгеләнгән эш бирүче һәм башка оешма яки индивидуаль эшмәкәр арасында төзелгән инвалидларны эшкә урнаштыру турында килешү нигезендә индивидуаль эшмәкәр белән хезмәт килешүе төзелгән очракта;

3) Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән башка очракларда.

12. Инвалидларны эшкә урнаштыру әлеге статьяның 11 өлешендәге 2 пунктында каралган инвалидларны эшкә урнаштыру турында килешүгә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы территориясендә эш бирүче (аның вәкиллеге, филиалы) урнашкан урында гамәлгә ашырылырга тиеш.»;

6) 4 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4 статья. **Инвалидларны эшкә урнаштыру өчен аерым эш төрләрен (һөнәрләр) резервлау**

1. Әлеге Законның 3 статьясындагы 2 һәм 3 өлешләрендә күрсәтелгән оешмалардан тыш, эш бирүчеләрдә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен аеруча уңайлы булган аерым эш төрләре (һөнәрләр) резервлана.

2. Инвалидларны эшкә урнаштыру өчен аеруча уңайлы булган аерым эш төрләрен (һөнәрләр) резервлау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

7) 5 статьяда:

а) исемдә «эш урыннары» сүзләрен «аерым эш төрләрен (һөнәрләр)» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Эш бирүчеләр тарафыннан аерым эш төрләре (һөнәрләр) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең хезмәт һәм мәшгульлек өлкәсендә вәкаләтле органы билгеләгән социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен резервлана .»;

в) 2 өлештә «резервланучы эш урыннары» сүзләрен «аерым эш төрләре (һөнәрләр) буенча резервланучы эш урыннары» сүзләренә алмаштырырга, «2 һәм 3 өлешләрендә» сүзләрен «2 өлештә» сүзләренә алмаштырырга, «эш бирүче хезмәткәрләренең исемлектәге уртача саныннан» сүзләре алдыннан «алдагы квартал өчен» сүзләрен өстәргә;

г) 3 өлештә «эш урыннары» сүзләрен «аерым эш төрләрен (һөнәрләр)» сүзләренә алмаштырырга;

8) 6 статьяда:

а) 1 өлешнең 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) инвалидларны башка оешма яки индивидуаль эшмәкәр белән төзелгән килешүгә ярашлы рәвештә инвалидларны эшкә алу өчен билгеләнгән квоталар хисабына башка эш бирүчеләрдәге эш урыннарына эшкә урнаштыру;»;

б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Эш бирүчеләр түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

1) инвалидларны эшкә алу өчен квотаны үтәргә, инвалидларны һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен аерым эш төрләрен (һөнәрләрне) резервларга;

2) түбәндәгеләр турында белешмәләр булган локаль норматив актларны кабул итәргә:

инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннары булдыру яки бүлеп бирү;

инвалидларны һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен резервланган аерым эш төрләре (һөнәрләр);

3) ай саен Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына инвалидларны эшкә кабул итү квотасы үтәлеше турында мәгълүматны бердәм цифрлы платформада яки Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган тәртип нигезендә мондый мәгълүмат урнаштырыла ала торган башка мәгълүмати ресурсларда урнаштыру юлы белән ай саен мәгълүмат бирергә;

4) инвалидларга инвалидларны индивидуаль реабилитацияләү яки абилитацияләү программасына ярашлы рәвештә хезмәт шартлары булдыру.»;

9) 7 статьяда:

а) 1 өлештә «резервланучы эш урыннары» сүзләрен «аерым эш төрләрен (һөнәрләрне) резервлаучы эш урыннары» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «резервланучы эш урыннары» сүзләрен «аерым эш төрләрен (һөнәрләрне) резервлаучы эш урыннары» сүзләренә алмаштырырга;

10) 8 статьяда «Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау» сүзләрен «Инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау һәм инвалидларны һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар эшкә урнаштыру өчен аерым эш төрләрен (һөнәрләр) резервлау» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

1. Әлеге Закон 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә, әлеге Законның 1 статьясының 4 пунктыннан тыш.

2. Әлеге Законның 1 статьясының 4 пункты 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**«Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектына**

# АҢЛАТМА

«Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты «Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында» 2006 елның 24 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 2023 елның 12 декабрендәге 565-ФЗ номерлы федераль законга (алга таба – Федераль закон) туры китерү максатларында эшләнгән.

Федераль закон нигезендә хезмәт базарының үзгәргән чынбарлыгын чагылдыруга, дәүләт бурычларын хәл итү өчен кирәкле нәтиҗәле инструментлар кертүгә, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарының халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә вәкаләтләрен конкретлаштыруга юнәлдерелгән нигезләмәләре каралган.

Моңа бәйле рәвештә закон проекты белән хезмәт базарында тигез шартларда ярыша алмаган һәм шуңа бәйле рәвештә эш эзләүдә кыенлыклар кичергән социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар категорияләре исемлеге төгәлләнә.

Федераль закон белән «аерым эш төрләрен (һөнәрләрне) резервлау» дигән яңа төшенчә кертелә. Моңа бәйле рәвештә Законның исемен үзгәртергә тәкъдим ителә.

Федераль законның 38 статьясының 1 өлеше нигезендә хезмәткәрләр саны 35 кешедән артып киткән эш бирүчеләргә Россия Федерациясе субъектының норматив хокукый акты нигезендә, халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен һәм норматив-хокукый җайга салуны гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан расланган методик тәкъдимнәргә ярашлы рәвештә, хезмәткәрләрнең уртача исемлек санының 2-4 проценты күләмендә инвалидларны эшкә алу өчен квота билгеләнә.

Татарстан Республикасында инвалидларны эшкә кабул итү өчен квота Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы эш бирүчеләр өчен хезмәткәрләрнең исемлек буенча уртача санының 2 һәм 3 проценты күләмендә билгеләнгән, бу федераль законнарда билгеләнгән нормалардан артмый.

**«Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары ИСЕМЛЕГЕ**

«Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

«Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарларына үзгәрешләр кертүне таләп ителәчәк:

«Эш бирүчеләрнең инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннары булдыруга чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2007 елның 5 февралендәге 32 номерлы карар;

«Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оешмаларда эш урыннарын квоталау тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» 2007 елның 4 маендагы 170 номерлы карар;

«Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан эш бирүчеләрдә эш урыннарын резервлау тәртибен раслау турында» 2007 елның 18 маендагы 194 номерлы карар.

**«Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектын**

# ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ

«Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итмәячәк.